ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2023 ел Баулы шәһәре № 202

2024 елга Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

“Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясынлагы 1 өлешендәге 11 пунктына, “Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларын норматив буенча финанслауны кертү турында” 2007 елның 11 декабрендәге 201 номерлы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карарына ярашлы Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2024 елга Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатларында тәрбияләнүчеләрне тотуга куелган норматив чыгымнарны расларга.

2. Баулы муниципаль районы финанс-бюджет палатасына, әлеге карарның 1 пунктында расланган, мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарына ярашлы рәвештә, мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы –
Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча беренче
урынбасары И.И. Хөснуллина

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 30 октябрендәге
202 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Баулы муниципаль районының
гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатлары
каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Гомуми белем бирү оешмасының төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә елына норматив чыгымнар, сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 107456 |
| | авыл җирлеге | 108826 |
| Гомуми белем бирү мәктәп-интернаты | шәһәр җирлеге | 158070 |
| | авыл җирлеге | 162608 |